**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«01» 02 2024 ел Яр Чаллы №312

«2024-2026 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культура һәм спортны үстерү» программасын раслау турында

2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисади үстеше стратегиясе (2019 елның 25 декабренә үзгәрешләр белән, ( 2019 елның 5 апрелендәге 31-ТРЗ номерлы, 2019 елның 25 декабрендәге 112-ТРЗ номерлы ТР Законнары редакциясендә), «2019-2026 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 159 номерлы карары (2019 елның 12 июлендәге 567 номерлы, 2019 елның 8 ноябрендәге 1023 номерлы, 2019 елның 30 декабрендәге 1279 номерлы, 2020 елның 12 июнендәге 483 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 1117 номерлы, 2021 елның 9 августындагы 693 номерлы, 2022 елның 12 маендагы 434 номерлы, 2022 елның 20 октябрендәге 1115 номерлы, 2023 елның 5 июнендәге 690 номерлыТР МК карарлары редакциясендә) нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2024-2026 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культура һәм спортны үстерү» район программасын расларга
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары вазифаларын башкаручы А.Г. Мәхмүтовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 01 02 312 номерлы карарына кушымта

**«2024-2026 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культура һәм спортны үстерү» программасы**

**Яр Чаллы шәһәре**

**2024 ел**

# ЭЧТӘЛЕГЕ

Программа паспорты

Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенең гомуми характеристикасы

Программаның максатлары һәм бурычлары

Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Гамәлѓә ашыру механизмы.

Программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү (бәяләү индикаторлары)

Программаны гамәлгә ашыру буенча чаралар

# ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2024-2026 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культура һәм спортны үстерү» (алга таба – Программа) |
| Дәүләт заказчысы | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның төп эшләүчесе | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| Программаны төп башкаручылар | - Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге;<br>- «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ;<br>- Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге;<br>- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тукай муниципаль районында социаль яклау бүлеге (килешү буенча);<br>- «Якты юл» («Светлый путь») район газетасы (килешү буенча);<br>- учреждениеләр, оешмалар, фондлар, иҗтимагый берләшмәләр (килешү буенча) |
| Программаның максатлары | - Тукай муниципаль районы халкында, беренче чиратта, балалар, яшүсмерләр һәм яшьләрдә сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру;<br>- системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче гражданнарның өлешен арттыру |
| Программаның бурычлары | Программа чаралары түбәндәге юнәлешләр буенча системалаштырыла:<br>- яшәү, уку, хезмәт эшчәнлеге урыны буенча халыкның төрле категорияләренә физик культура, спорт белән шөгыльләнү өчен уңайлы шартлар булдыру;<br>- физик активлыкны һәм сәламәт яшәү рәвешен системалы пропагандалауны оештыру,<br>- социаль әһәмиятле авыруларны профилактикалау, гомуми авырулар санын киметү;<br>- яшьләрдә алкоголь, тәмәке һәм башка психотроп матдәләр куллануга аңлы рәвештә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары | 2024-2026 еллар |
| Программаны еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп финанслау күләме | 2024-2026 елларда программаны финанслауның гомуми күләме 6 768 000 сум тәшкил итәчәк,шул исәптән:<br>2024 елда - 2 256 000 сум;<br>2025 елда - 2 256 000 сум;<br>2026 елда - 2 256 000 сум.<br>Программаны финанслау күләме фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын |

| | |
|---|---|
| | формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>Республика, федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганак акчалары ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк |
| Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 2026 елга түбәндәгеләргә ирешү күздә тотыла:<br>- Тукай муниципаль районы халкының уртача гомер озынлыгын һәм тормыш сыйфатын арттыру;<br>- Тукай муниципаль районы халкында, беренче чиратта, балалар, яшүсмерләр һәм яшьләрдә сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру;<br>- халыкта үз сәламәтлегенә сак караш, сәламәт яшәү рәвешенә омтылу формалаштыру;<br>- социаль әһәмиятле авыруларны профилактикалау, гомуми авырулар санын киметү;<br>- яшьләрдә алкоголь, тәмәке һәм башка психотроп матдәләр куллануга аңлы рәвештә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру. |

## I. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенең гомуми характеристикасы, шул исәптән программа хәл итүгә юнәлтелгән проблемалар

«2024-2026 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасы 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисади үстеше стратегиясе (2019 елның 25 декабренә үзгәрешләр белән, (2019 елның 5 апрелендәге 31-ТРЗ номерлы, 2019 елның 25 декабрендәге 112-ТРЗ номерлыТР Законнары редакциясендә), «2019-2026 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 159 номерлы карары (2019 елның 12 июлендәге 567 номерлы, 2019 елның 8 ноябрендәге 1023 номерлы, 2019 елның 30 декабрендәге 1279 номерлы, 2020 елның 12 июнендәге 483 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 1117 номерлы, 2021 елның 9 августындагы 693 номерлы, 2022 елның 12 маендагы 434 номерлы, 2022 елның 20 октябрендәге 1115 номерлы, 2023 елның 5 июнендәге 690 номерлыТР МК карарлары редакциясендә) нигезендә эшләнде.

Тукай муниципаль районы халкы арасында физик культураны, спортны һәм сәламәт яшәү рәвешен үстерү буенча кабул ителгән программаларны гамәлгә ашыру чорында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче халык саны үсешендә уңай динамика билгеләнә, ул 2024 ел башына 29149 кеше тәшкил итте.

Район ярышларын, күп баскычлы система буенча физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт-массакүләм чаралар үткәрү системасы формалаштырылган (хезмәт, уку коллективыннан алып республика дәрәҗәсендәге ярышларда катнашуга кадәр).

Район командалары республикада уздырыла торган 60тан артык спорт-массакүләм чараларда катнаша.

Шулай ук район халкы «Татарстан чаңгы юлы», «Татарстан кроссы» кебек Бөтенроссия массакүләм ярышларында, ГТО фестивальләрендә һ.б. актив катнаша.

Катнашучылар арасында иң популяр спорт төрләре булып чаңгы узышлары, волейбол, мини - футбол, шашка, шахмат, шайбалы хоккей тора.

Предприятие, оешма җитәкчеләре, муниципаль хезмәткәрләр арасында Спартакиада үткәрү традициягә әверелде. 2023 елда районның авыл җирлекләре, предприятиеләре һәм оешмалары арасында 13 спорт төре буенча V Спартакиада узды, анда районның барлык авыл җирлекләре һәм 16 оешмасы актив катнашты. Чарага 622 кеше җәлеп ителде.

Районда 188 спорт объекты эшли. Сосновый Бор поселогында «Яшьлек» универсаль спорт залы, Түбән Суыксу авылында «Алга» универсаль спорт залы, Круглое Поле поселогында «Акчарлак» ябык йөзү бассейны, 24 яңа универсаль спорт мәйданчыгы һәм ГТО нормативларын үтәүгә әзерләнү өчен кече спорт мәйданчыгы, Яңа поселогында 3 км озынлыктагы яктыртылган чаңгы трассасы белән чаңгы-биатлон үзәге һәм 1 км озынлыктагы чаңгы-роллер трассасы, 6000 м озынлыктагы трасса белән «Наиком экстрим мотокросс» балалар спорт - техник клубы уңышлы файдаланыла.

Физик культура һәм спортның роле халыкның сәламәтлеге торышын билгеләүче һәм һәр гражданның бөтен гомере дәвамында оптималь физик активлыкка ярдәм итүче сизелерлек социаль һәм сәяси факторга әверелә бара. Физик культура һәм спорт белән оештырылган һәм мөстәкыйль шөгыльләнү процессында шулай ук социаль адаптация, әхлакый сәламәтләндерү, эстетик тәрбия, милли кыйммәтләр һәм мәдәниятләр системасына тарту проблемалары хәл ителә.

Физик культура һәм спортны алга таба үстерү өчен эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләре булып тора:

балалар-яшүсмерләр һәм яшьләр спорты системасын үстерү һәм камилләштерү;

халыкны физик культура һәм спорт белән актив шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен районның барлык торак пунктларында массакүләм спорт системасын үстерү;

район халкының социаль куркынычсыз һәм икътисади яктан отышлы яшәү мохите буларак сәламәт, актив яшәү рәвешен формалаштыруның стимуллаштыручы шартларын үстерү;

физкультура-спорт корылмаларын эксплуатацияләү һәм үстерү нәтиҗәлелеген арттыру.

Программа район территориясендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә, җирле үзидарә органнарының, барлык милек формасындагы предприятиеләрнең, оешмаларның, мәктәпләрнең, халыкның физик әзерлеген һәм сәламәтлек дәрәҗәсен күтәрү буенча бурычларны хәл итүдә тырышлыкларын берләштерергә һәм барлык юнәлешләр буенча физик культура һәм спорт өлкәсенә дәүләт ярдәмен тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

## II. Программаның төп максатлары һәм бурычлары, программа чаралары, көтелгән ахыргы нәтиҗәләрне тасвирлау, гамәлгә ашыру вакыты

Программаның максатлары:

- Тукай муниципаль районы халкында, беренче чиратта, балалар, яшүсмерләр һәм яшьләрдә сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру,

- системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче гражданнарның өлешен арттыру.

Программаның максатларына ирешү өчен, түбәндәге бурычларны хәл итәргә

кирәк:

- яшәү, уку, хезмәт эшчәнлеге урыны буенча халыкның төрле категорияләренә физик культура, спорт белән шөгыльләнү өчен уңайлы шартлар булдыру.

- физик активлыкны һәм сәламәт яшәү рәвешен системалы пропагандалауны оештыру,

- социаль әһәмиятле авыруларны профилактикалау, гомуми авырулар санын киметү,

- яшьләрдә алкоголь, тәмәке һәм башка психотроп матдәләр куллануга аңлы рәвештә тискәре мөнәсәбәт формалаштыру.

Программаны гамәлгә ашыру срогы: 2024-2026 еллар.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

2024-2026 елларда программаны финанслауның гомуми күләме 6 768 000 сум тәшкил итәчәк,шул исәптән:

2024 елда - 2 256 000 сум;

2025 елда - 2 256 000 сум;

2026 елда - 2 256 000 сум.

Ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

Республика, федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганак акчалары ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.

## IV. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаны хәл итү өчен түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру каралган:

1. Массакүләм мәгълүмат чаралары аша, Интернет челтәре аша, басма продукция аша һәм тышкы реклама чаралары аша, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлтелгән мәгълүмати-белем бирү кампанияләре үткәрү юлы белән, халыкның мәдәни-күңел ачу тормышы элементлары аша, өлкәннәрнең билгеле бер төркемнәрен диспансерлаштыру буенча чараларны актив гамәлгә ашыру аша, яшьләрнең, иҗтимагый, дини оешмаларның һәм һөнәри берләшмәләрнең халыкка тәмәке тарту, исерткеч эчемлекләр куллану сәламәтлегенә начар йогынты ясау турында мәгълүмат бирүендә катнашуын киңәйтү аша сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау.

2. Халыкны тәмәке тартудан һәм алкоголь кулланудан баш тартуга этәрү максатыннан мәгълүмат кампанияләре һәм массакүләм акцияләр үткәрү.

3. Тукай районы халкында физик активлык дәрәҗәсен, рациональ туклануга бирелгәнлекне арттыру, психоэмоциональ йөкләнеш дәрәҗәсен киметү.

4. Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, халыкның алкоголизмын киметүгә юнәлтелгән массакүләм акцияләр үткәрү.

Программаны гамәлгә ашыру сәламәтлекнең актуаль проблемалары, шул исәптән сәламәт яшәү рәвеше, сәламәтлекне актив саклау һәм ныгыту, мәдәният дәрәҗәсе һәм сәламәтлек потенциалы, тормыш сыйфаты һәм Тукай муниципаль районы халкының уртача гомер озынлыгын арттыру буенча халыкның мәгълүматлылыгын арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге күрсәткечләрне кулланырга тәкъдим ителә:

- халыкның сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча, шул исәптән алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәкене артык куллануның зыяны турында массакүләм мәгълүмат чараларында басылган мәкаләләр саны;

- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча массакүләм акцияләр саны;

- гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санынннан акциядә катнашучы укучыларның өлеше.

Программаның координаторы булып муниципаль район Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге тора, ул тармак бүлекләре һәм идарәләре, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар белән берлектә:

- билгеләнгән тәртиптә программа чаралары исемлеген аларны, гамәлгә ашыру чыгымнарын төгәлләштерү, шулай ук программаны гамәлгә ашыру механизмы турында тәкъдимнәр әзерли;

- максатлы индикаторлар исемлеген һәм аларның квартал буенча бүленешен төгәлләштерә.

## V. Программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны гамәлгә ашыруның социаль-икътисади нәтиҗәлелеге район халкының төрле төркемнәренең авыру дәрәҗәсен киметүне халыкның сәламәтлеген ныгытуны һәм тормыш сыйфатын күтәрүне, сәламәт яшәү рәвешенә юнәлтелгән профилактик чараларга халыкны җәлеп итүне арттыруны, Тукай муниципаль районы халкы арасында алкогольле продукция, сыра һәм тәмәке куллануны киметүне күздә тотыла.

Бәяләү индикаторлары

| Күрсәткечләр: | 2024 | 2025 | 2026 |
|---|---|---|---|
| Системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче гражданнарның өлешен арттыру | 63,5% | 64% | 65% |
| Балаларны һәм яшьләрне физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү дәрәҗәсе | 75% | 76% | 77% |
| Массакүләм акцияләр саны | 28 | 29 | 30 |
| Массакүләм мәгълүмат чараларында (радио, телевидение, матбугат) урнаштырылган мәгълүмат материаллары саны | 36 | 38 | 40 |
| Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми санынннан акциядә катнашучы укучыларның өлеше | 75 | 80 | 85 |
| Сәламәтлеккә ярдәм итүче гомуми белем бирү оешмаларының өлеше | 100 | 100 | 100 |

**«2024-2026 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, физик культура һәм спортны үстерү» программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар**

| № | Чараларның исеме | Финанс средстволарын бүлү | | | Финанслау чыганагы | Башкаручы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2024 | 2025 | 2026 | | |
| 1. | Халыкның сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча, шул исәптән алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәкене артык куллануның зыяны турында мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту | | | | агымдагы финанслау | «Татмедиа» АҖ филиалы - «Якты юл «Светлый путь» газетасы редакциясе |
| 2. | Программаның иң әһәмиятле чаралары турында мәгълүматны муниципаль районның рәсми сайтында урнаштыру | | | | финанслау таләп ителми | Муниципаль район Башкарма комитеты |
| 3. | Социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны тикшерү буенча рейдлар үткәрүне оештыру | | | | финанслау таләп ителми | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия |
| 4. | Профилактика системасы хезмәтләре исәбендә торучы гаиләләрнең район мәгълүмат банкын системалы рәвештә яңарту | | | | финанслау таләп ителми | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия |
| 5. | Психиатр-наркологның авыл җирлекләрендә планлаштырылган күчмә лекцияләре, темалар:<br>- алкоголь, сыра куллануны профилактикалау;<br>- тәмәке һәм тәмәке катнашмаларын тартуны профилактикалау;<br>- яшүсмерләрнең суицид тәртибен профилактикалау;<br>- наркотикларга бәйлелек куркынычы факторларын кисәтү | | | | агымдагы финанслау | «Тукай РҮХ» ДАССУ Психиатр-нарколог |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Акушер-гинекологның планлаштырылган күчмә лекцияләре, темалар:<br>- яшүсмер кызлар арасында иртә йөклелекне профилактикалау, гаилә кыйммәтләрен формалаштыру;<br>- барысы да хатын-кыз организмы турында;<br>- аналык муенчыгы яман шешен профилактикалау;<br>- күкрәк яман шешен профилактикалау | | | | агымдагы финанслау | «Тукай РҮХ» ДАССУ Акушер-гинеколог |
| 7. | Инфекционистның планлаштырылган күчмә лекцияләре, темалар:<br>- «ВИЧ-инфекция һәм СПИД»;<br>- «Куркынычсызлык - безнең сайлау» | | | | агымдагы финанслау | «Тукай РҮХ» ДАССУ Инфекционист |
| 8. | Терапевтларның планлаштырылган күчмә лекцияләре, темалар:<br>- эчәк яман шешен профилактикалау;<br>- йөрәк-кан тамырлары авыруларын профилактикалау | | | | агымдагы финанслау | «Тукай РҮХ» ДАССУ Терапевт |
| 9. | Тәмәке тартуның зыяны һәм нәтиҗәләре турында визуаль мәгълүмат урнаштыру | | | | агымдагы финанслау | «Мәгариф идарәсе» МКУ, мәдәният бүлеге |
| 10. | Тәмәке тартуның зыяны һәм нәтиҗәләре турында визуаль мәгълүмат урнаштыру | | | | агымдагы финанслау | Мәдәният бүлеге |
| 11. | Ел саен 31 майда Бөтендөнья тәмәке төтененнән башка көнен үткәрү, тематик викториналар, конкурслар, иҗади эшләр күргәзмәләре үткәрү белән профилактик акция оештыру | | | | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | Мәдәният бүлеге |
| 12. | Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча мәдәни-массакүләм чаралар үткәрү | 20000 | 20000 | 20000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | Мәдәният бүлеге, район үзәк хастаханәсе |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 13. | Балаларны яклау көне | 36000 | 36000 | 36000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | Мәдәният бүлеге |
| 14. | Тәмәке тарту, алкоголь продукциясе куллану, сыраның зыяны турында китапханәләрдә китап-иллюстрация күргәзмәләрен оештыру | | | | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | Мәдәният бүлеге |
| 15. | Алкоголь продукциясен куллануны һәм социаль тискәре күренешләрне профилактикалау буенча түгәрәк өстәлләр, акцияләр үткәрү | | | | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | Мәдәният бүлеге |
| 16. | Гаилә һәм тугрылык көненә багышланган чаралар | 5000 | 5000 | 5000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | Мәдәният бүлеге, ГХАТ |
| 17. | Яшәү урыны буенча төрле яшьтәге халыкның киң катнашында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт-массакүләм чаралары үткәрү | 611700 | 611700 | 611700 | «Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» МБУ | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| | | 100000 | 100000 | 100000 | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ | |
| 18. | Район мәгариф учреждениеләре, авыл җирлекләре арасында физкультура-савыктыру һәм спорт-массакүләм эшне иң яхшы оештыруга смотр-конкурслар үткәрү | 125000 | 125000 | 125000 | «Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» МБУ | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 19. | Район мәгариф учреждениеләренең спорт секцияләре һәм түгәрәкләре эшен оештыру, Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ бүлекчәләренең матди базасын ныгыту | 70617 | 70617 | 70617 | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ |
| | | | | | Республика бюджеты | |
| 20. | Район территориясендә физик культура, массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыруга бәйле чаралар, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру (аутсорсинг) | 100000 | 100000 | 100000 | Җирле бюджет | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ |
| | | | | | Республика бюджеты | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 21. | Спорт корылмаларының, балалар һәм яшүсмерләр яшәү урыны буенча кызыксыну буенча клубларның даими эшен, өстәмә белем бирү белән мәшгульлекне тәэмин итү | | | | агымдагы финанслау | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 22. | Яшәү урыны буенча «хавеф төркеме» балалары һәм яшүсмерләре белән эш оештыру | | | | агымдагы финанслау | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 23. | ТР, РФ беренчелекләрендә, чемпионатларында, спорт төрләре буенча бөтенроссия ярышларында һәм турнирларында катнашу (яшәү, туклану чыгымнары) | 686683 | 686683 | 686683 | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 24. | Спорт төрләре буенча мәгариф хезмәткәрләре спартакиадасы | 33000 | 33000 | 33000 | «Мәгариф идарәсе» МКУ | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 25. | «Мәктәп волейбол лигасы» волейбол турниры | 35000 | 35000 | 35000 | «Мәгариф идарәсе» МКУ | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 26. | Мәктәп спорт клублары | 35000 | 35000 | 35000 | «Мәгариф идарәсе» МКУ | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 27. | «КЭС-БАСКЕТ» мәктәп баскетбол лигасы чемпионаты | 35000 | 35000 | 35000 | «Мәгариф идарәсе» МКУ | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 28. | «Президент ярышлары» бөтенроссия ярышлары | 35000 | 35000 | 35000 | «Мәгариф идарәсе» МКУ | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 29. | «Президент спорт уеннары» бөтенроссия ярышлары | 35000 | 35000 | 35000 | «Мәгариф идарәсе» МКУ | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 30. | «Куркынычсыз тәгәрмәч» республика конкурсының муниципаль этабы | 17000 | 17000 | 17000 | «Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге» ӨББМБУ | Мәгариф идарәсе |
| 31. | Мәгариф оешмалары укучылары арасында чаңгы туризмы буенча ярышлар | 17000 | 17000 | 17000 | «Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге» ӨББМБУ | Мәгариф идарәсе |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 32. | «Алтын көз» спорт туризмы буенча ярышлар | 9000 | 9000 | 9000 | «Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге» ӨББМБУ | Мәгариф идарәсе |
| 33. | «Бөтен гаилә белән стартка!» ата-аналар катнашында спорт бәйрәме | 17000 | 17000 | 17000 | «Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге» ӨББМБУ | Мәгариф идарәсе |
| 34. | ТР мәктәп укучылары спартакиадасы һәм спорт туризмы кысаларында мәктәп укучылары арасында район һәм республика ярышлары | 155000 | 155000 | 155000 | «Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге» ӨББМБУ | Мәгариф идарәсе |
| 35. | «Ел символы» район декоратив-кулланма иҗат конкурсы | 33000 | 33000 | 33000 | «Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге» ӨББМБУ | Мәгариф идарәсе |
| 36. | Биатлон буенча ярышлар | 45000 | 45000 | 45000 | «Тукай муниципаль районы мәктәптән тыш эшләр үзәге» ӨББМБУ | Мәгариф идарәсе |
| | БАРЛЫГЫ | 2 256 000 | 2 256 000 | 2 256 000 | | |